# Мәңге яшь Тукай

Шагыйрь – халык йөрәгендә

Альбина **КЕЛЬШ**

**24 апрельдә, халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көне якынлашкан көндә, шәһәр Мәдәният сараенда район күләмендәге “Мәңге яшь Тукай” бәйгесе үтте.**

Конкурста шәһәрнең төрле мәктәпләре укучылары, шагыйрь иҗатын сөюче өлкәннәр катнашты.

Чараны Алабуганың татар халык театры җитәкчесе Нина Сәлимулина ачып җибәрде.

– Без бүген күчеш, күтәрелеш чорын кичерәбез. Гасыр башында – җәмгыятьнең кискен борылыш чорында – Тукайны борчыган сораулар бүген безне дә борчый, алар бүген дә актуаль. Аның иҗатында бүгенге көннең күп кенә сорауларына җавап табып була, шуңа күрә Тукай безгә һәрчак бик якын, – дип билгеләп үтте Нина ханым.

Чараның тәүге өлешендә, залны сихри моңга күмеп “Тәфтиләү” көе яңгырады. Милли аһәң белән сугарылган халык көе һәркемнең күңеленә якты нур булып иңде.

Бөек шагыйребезнең үлмәс әсәрләре, шулай ук Тукайга багышлап үзләре иҗат иткән шигырьләре белән чыгыш ясарга әзерләнгән катнашучылар берәм-берәм жюри әгъзалары һәм килгән кунаклар алдына чыгарга әзерләнде.



“Тукайны укыйбыз” номинациясендә Риналь Закиров 1нче дәрәҗә диплом белән бүләкләнде. / ФОТО: АЛЬБИНА КЕЛЬШ.

*Мәңгелек илһам*

*Дәшеп безне алга таба,*
*Тукай аты чабып бара,*
*Син атыңда һич калышмый,*
*Егылмый юыртып кара.*

*Чаптар аттай дәртле рухы*
*Ияртмәкче үз артыннан.*
*Үтә еллар, үтә гасыр –*
*Ә ул дәшә бик якыннан.*

*Күңелләргә үтеп керә –*
*Ул һәркемгә гүя яшьтәш,*
*Сабыймы син, аксакалмы –*
*Ишетелә бер-бер киңәш.*

*Иярләнгән күпме зиһен,*
*Зирәклек Тукай атына!*
*Шагыйрь даны, даһилыгы –*
*Мәңгелек илһам халкыма.*

**Гөлзадә Әхтәмова**

Иң кечкенә катнашучылардан алып, өлкән яшьтәгеләргә кадәр, барысы да бәйгегә нык клап әзерләнгән, һәммәсе сәнгатьле сөйләм һәм дә сәхнә осталыгын күрсәттеләр. Биредә җыр җырлаучы, шигырь укучылар да, шагыйрь әсәрен сәхнәләштерүчеләр дә булды.

Бөек Тукаебыз язып калдырган шигъри юллар кабат-кабат яңгырады, алардагы тормыш хакыйкате бүгенге заман кешесенә үгет-нәсыйхәт булып ирешә.

Конкурс номерларыннан тыш, шәһәребезнең “Ак каз”, “Сөембикә” ансамбльләре чыгышларын карап хозурланды тамашачылар. Бәйге генә түгел, бәйрәм булды бу, дисәк, ялгыш булмас.

Үз талантларын күрсәткән һәр катнашучы лаеклы бәя алып, 1нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә дипломнар белән бүләкләнде.

“Тукайны укыйбыз” номинациясендә 14 яшькә кадәрге балалар арасында җиңүчеләр булып Риналь Закиров һәм Зөһрә Фәтхуллина танылды. Өлкәннәр арасында исә “Тукай турында укыйбыз” номинациясендә 1 нче дәрәҗә диплом белән Әнисә Һадиуллина, “Тукайны укыйбыз” номинациясендә 1 нче дәрәҗә диплом белән Лира Ибраһимова бүләкләнде.

Чараны йомгаклап, жюри рәисе, “Чулман” әдәби берләшмәсе җитәкчесе Тәҗрия Җәләева сүз алды.

– Иң элек барлык катнашучыларга рәхмәтемне белдерәсем килә. Бүген аларның шундый матур, чиста татар телендә чыгыш ясаулары бик куандыра. 20 нче гасыр башында татар телендә төрки, гарәп, фарсы алынмалары күп булган, шуңа күрә укырга авыр, бигрәк тә балалар өчен. Тукай шушы татар телен чиста татар әдәби теленә әйләндерүче шәхесебез ул. Тукай безгә татар телен биргән, ә без аны дәвам итәргә тиеш. Әлеге бәйгене оештыручы Нина Сәлимуллинага бик зур рәхмәт, бу бик зур һәм әһәмиятле эш. Мондый бәйгеләр үткәрелсә, татар теленең дәрәҗәсе үсә барыр, – диде Тәҗрия ханым.

Билгеләп үтик, әлеге конкурс Алабуганың татар халык театры башлангычы белән һәм шәһәр Мәдәният сарае хуплавында быел беренче мәртәбә уздырылды. Тукай мирасын, татар телен саклап калу һәм киләчәк буынга җиткерү өчен бик әһәмиятле, тәрбияви-әхлакый кыйммәте гаять зур булган мондый чаралар алга таба да уңышлы үтәр, катнашучылар да елдан-ел артып торыр дип ышанабыз.

# “Балалар китапханәнең ачылуын түземсезлек белән көтә”

Илкүләм проект

Валентина **ЗАМЯТИНА**

**Газетабызның бер санында без Алабуга үзәк балалар китапханәсе “Мәдәният” илкүләм проекты кысаларында үткәрелгән “Модельле муниципаль китапханәләр төзү” конкурсында җиңүче булды дип язган идек. Ә бу язмада без мондый гадәти булмаган китапханәне булдыру эшләренең барышы белән таныштырырбыз.**




Интерактив комплекс – модель китапханәнең аерылгысыз атрибуты. / ФОТО: ВАЛЕНТИНА ЗАМЯТИНА.

Балалар өчен модель китапханә малайларны һәм кызларны һәрьяклап үстерү өчен мөмкинлекләр тәкъдим итә. Анда китаплардан тыш, балалар һәм китапханә хезмәткәрләре өчен кирәкле заманча җиһазлар да булачак.

Хәзерге вакытта китапханәгә күп функцияле интерактив комплекс кайтарылган.

– Интерактив комплекс ярдәмендә видеоконференцияләр, мастер-класслар, башка китапханәләр белән вебинарлар, шулай ук дәрестән тыш чаралар үткәрергә мөмкин. Биредә балаларны һәрьяклап үстерергә ярдәм итүче уеннар, шулай ук рәсем ясау мөмкинлеге каралган, – ди Алабуганың Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры Юлия Нәҗипова.

Китапханәдә китаплар бирүне электрон форматта күзәтергә мөмкинлек бирүче җиһаз барлыкка килде.

– Якын арада китапханәгә яңа компьютерлар, виртуаль шлемнар, планшетлар, интерактив идән һәм сенсор өстәлләр кайтырга тиеш, – ди Юлия Нәҗипова.

Модель китапханәдә заманча йорт җиһазлары да куелачак, аларның бер өлеше дизайн-концепция кысаларында индивидуаль эшләнә.

– Хәзерге мебель уңайлы түгел. Без “ДетскийЧитайМир” өчен заманча, якты, уңайлы, якты җиһазлар сатып алырга ниятлибез, – дип өстәде Юлия Владимировна.

Модель китапханәдә курчаклар, машиналар, конструкторлар, шулай ук балалар һәм ата-аналар өчен өстәл уеннары да булачак. Кыскасы, китапханә гаилә белән ял итү урыны булырга тиеш.

– Модель китапханәнең бу детальләре зур игътибар таләп итә, әмма иң зур игътибар, Казан һәм Мәскәү коллегаларыбызның тәҗрибәсенә таянып, яңа заманча китаплар сайлап алуга юнәлдерелә. Шуңа да яңартылган китап фонды модель китапханәнең барлык таләпләренә җавап бирәчәк. Китап һичшиксез яңа булырга тиеш, әдәби әсәрләр романнан алып комикска кадәр төрле жанрларда тәкъдим ителәчәк, – ди Юлия Нәҗипова.

Ике ай дәвамында китапханә хезмәткәрләре сатып алу өчен китаплар исемлеген төзегән. Һәм нәкъ шул вакытта китапларның модель китапханәдә оештырылачак локация һәм клубларга туры килергә тиешлеге аңлашыла.

– Әйтик, без яшь ата-аналар клубы оештырырга ниятлибез. Моның өчен психология һәм педагогика буенча махсус әдәбият сайлап алынган. Гомумән, китаплар бик күп булачак, балалар китапханәсе фондының яртысы диярлек яңартылачак, – дип билгеләп үтә Юлия Владимировна.

Бик зур күләмдә эшләр башкарылган, ә аның нәтиҗәсен алабугалылар быел сентябрь ахырында күрә алачак.

– Без китапханәдә барган үзгәрешләргә сокланабыз. Мондый яңартуга барысы да шат. Балалар түземсезлек белән эшебезнең нәтиҗәсен көтәләр, яңалык булачагын беләләр. Үзгәрешләрне күреп зур тәэсирләр алсыннар өчен, аларга бар серне дә ачып бетермибез, – диде Юлия Нәҗипова.

*Безнең илдә илкүләм проектлар 2019 елдан Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин инициативасы белән гамәлгә ашырыла.*

Мәгълүмат

**Бәйрәм көннәрендә медицина учреждениеләренең эш графигы**

**27 апрель эш көне булганлыктан, медицина хезмәткәрләренең бу эш атнасы 1 көнгә озынрак булачак. Ә менә 28, 29, 30 апрель, шулай ук 1, 9, 10 май – ял һәм эшләми торган бәйрәм көннәре булып санала.**

Исегезгә төшерәбез, ашыгыч медицина ярдәме бригадалары чакыруларны тәүлек әйләнәсе кабул итә. “Ашыгыч ярдәм”гә шалтыратыр алдыннан үз хәлегезне бәяләгез һәм Алабуга үзәк район хастаханәсе һәм травматология пункты табибларының эш тәртибе белән танышыгыз.

**Травматология пункты:**

– 27 апрельдә 8.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр эшли;

– 29 апрельдә шимбә графигы буенча 8.00 дән 14.00 гә кадәр;

– 28, 30 апрель һәм 1, 9, 10 май – ял көннәре.

**Балалар поликлиникасы:**

– 27 апрельдә эш сәгате 7:30-19:00 гә кадәр; табибны өйгә чакырулар 07.30дан 12.00гә кадәр кабул ителә;

– 29 апрельдә шимбә графигы буенча 7.30 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр эшли; чакырулар 07.30 дан 12.00 гә кадәр кабул ителә;

– 28, 30 апрель һәм 1, 9, 10 май – ял көннәре.

**Балалар поликлиникасы филиалы:**

– 27 апрельдә 7:30-16:00гә кадәр эшли; чакырулар 07.30 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр кабул ителә;

– 28, 29, 30 апрель һәм 1, 9, 10 май – ял көннәре.

**Алабуга үзәк район хастаханәсе поликлиникасы:**

– 27 апрель тулы эш көне;

– 29 апрельдә шимбә графигы буенча эш көне;

– 8 майда эш көне 1 сәгатькә кыскартыла;

– 11 майда шимбә графигы буенча эш көне;

– 28, 30 апрель һәм 1, 9, 10 май – ял көннәре.

**Валентина ЗАМЯТИНА әзерләде**